КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2018 ел, 21 июнь г.Казань № 503

Татар ССР Министрлар Советының «Татар ССРда аналарга һәм балаларга социаль ярдәм күрсәтү буенча өстәмә чаралар турында» 1991 ел, 14 июнь, 261 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татар ССР Министрлар Советының «Татар ССРда аналарга һәм балаларга социаль ярдәм күрсәтү буенча өстәмә чаралар турында» 1991 ел, 14 июнь, 261 нче карарына (Татар ССР Министрлар Кабинетының 1992 ел, 12 декабрь, 83 нче карары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 1998 ел, 24 декабрь, 777 нче, 2001 ел, 17 декабрь, 907 нче, 2003 ел, 23 декабрь, 667 нче, 2017 ел, 28 март, 193 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

5 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5. Эш бирүчеләргә 16 яшькәчә балалары булган хатын-кызларга атна саен эш бирүче акчасы исәбеннән өлешчә яки тулысынча түләнә торган кимендә 2 сәгать ирекле вакыт яки айга 1 ирекле көн бирергән тәкъдим итәргә.

Хатын-кызларга ирекле вакыт яки ирекле көн бирү тәртибе һәм шартлары эш бирүчеләр кабул итә торган локаль норматив актлар һәм хезмәт законнары нигезендә күмәк шартнамәләр белән билгеләнә.

Тулы булмаган эш вакыты шартларында эшләгән яки еллык түләүле ялда, 3 яшькәчә баланы тәрбияләү ялында булган хатын-кызларга әлеге ташламалар кагылмый. Ирекле вакытны кушу рөхсәт ителми.»;

13 пункт үз көчен югалткан дип танырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин